СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.04.2019г. с.Соболевское № 66-274

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) законга һәм муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Советы
карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына:

үз норма чыгару эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы затлар тарафыннан билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларның законнарга, муниципаль берәмлекләр Уставларына туры килүен системалы контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында мониторинг үткәрүне тәэмин итә торган муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Башлыгы О.Н.Майорова